ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**19.04.2023** **Чистай шәһәре** **№ 235**

2023 елның II кварталында
Чистай муниципаль районы буенча
гомуми торак мәйданының 1 квадрат метры
бәясе турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 03 октярендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгының 2023 елның 26 мартындагы 1333/исх-РС номерлы хаты һәм «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр союзы» Коммерциячел булмаган партнерлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында торак күчемсез милек базарын эксперт-аналитик тикшерүенә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2023 елның II кварталында Чистай муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының 1 квадрат метры бәясе (сумнарда) нормативын 74 337,50 (җитмеш дүрт мең өч йөз утыз җиде) сум, 50 тиен күләмендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Торак сәясәте бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://chistopol.tatarstan.ru).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы П.Б. Емельянов